КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.10.2025 № 492-П

Татарстан Республикасы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында кертү, аның территориясе чикләрен һәм саклау предметын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2025 елның 28 августындагы уңай бәяләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты (объектның төре – һәйкәл) сыйфатында кертергә.

2. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын саклау
комитетының 10.10.2025 ел,
№492-П боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты
**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чиге |
| • 1 | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - КМБДР белешмәләре буенча җир кишәрлекләре чикләре |
| **16:38:010509:8** | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |

Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **текстлы тасвирламасы**

Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза:

| Чикне узу | | Чикне узуның тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | Приволжская ур. ягына таба җир кишәрлегенең кадастр чиге буенча көнчыгыш юнәлештә 1 ноктасыннан 2 ноктасына кадәр; |
| 2 | 4 | Горький ур. ягына таба көньяк юнәлештә көнчыгыш юнәлешендә 2 ноктасыннан 4 ноктасына кадәр |
| 4 | 5 | җир кишәрлегенең эчке чиге буенча көнбатыш юнәлешендә 4 ноктасыннан Свердлов ур. ягына таба параллель рәвештә Горький ур. ягына 5 ноктасына кадәр |
| 5 | 1 | төньяк юнәлештә 5 ноктасыннан Свердлов ур. буенча 1 ноктасына кадәр |

Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш.,
Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**характерлы нокталары таблицасы**

| Нокта № | Җирле координаталар системасындагы нокта координаталары (МСК-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 380785.45 | 1287783.37 |
| 2 | 380784.41 | 1287797.09 |
| 3 | 380781.58 | 1287796.88 |
| 4 | 380775.51 | 1287795.97 |
| 5 | 380776.44 | 1287781.56 |
| 6 | 380783.13 | 1287783.15 |
| 1 | 380785.45 | 1287783.37 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын саклау
комитетының 10.10.2025 ел,
№492-П боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870-1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын

**саклау предметы**

1. Тарихи төзелеш структурасында шәһәр төзелеше һәм композицион характеристикалар, объектның Свердлов урамындагы кызыл линия буенча урнашуы.
2. Бина планында турыпочмаклы бер катлы кирпеч турыпочмаклы бинаның күләм-планлаштыру структурасы.
3. Конструктив схемасы: чын кирпеч диварлар; уемнарның чын кирпеч тоташтырмалары.
4. Тарихи конфигурациясе, биеклек билгеләре һәм иңкү түбәсенең конструктив чишелеше, түбә материалы – ике фальцлы табаклы түбә тимере.
5. Бина фасадларының архитектур бизәлеше:


1) төп фасад: төп фасадның үзәк уемы җәя формасында, калаклар белән кысаланган һәм ике ягында да җәя формасындагы тәрәзә уемнары белән симметрияле композиция, чыгып торган цоколь, йозак ташы һәм иңбашлары булган өчпочмаклы сандриклы катлаулы булмаган йөзлекләр белән кысаланган җәя формасындагы тәрәзә уемнары, тәрәзә төбендәге филенкалы турыпочмаклы куышлар, почмаклы рустован калаклар, бизәкләр тасмасы булган баскычлы кәрниз, иңбашлары һәм аркалы үзәк куышы булган кәкре сызыклы аттик һәм сохари белән тәмамланучы кәрниз, почмак баганалары булган парапет койма;



2) ян фасад: баскычлы кәрниз, бизәкләнеш (кирпеч буенча буяу).




6. Металл тәрәзә капкачлары һәм фурнитура һәм кыстыргыч элементлары белән капкалар.



*Саклау предметы комплекслы һәм фәнни тикшеренүләр, реставрация эшләре нәтиҗәләре буенча үзгәртелергә мөмкин.


Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Тәтеш ш., Свердлов ур., 55 й. адресы буенча урнашкан «Сәүдә киштәсе», 1870 -1880 еллар региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметы таблицасы

| Т/с | Саклау предметы | Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар |
|---|---|---|
| 1. | Тарихи төзелеш структурасында шәһәр төзелеше һәм композицион характеристикалар, объектның Свердлов урамындагы кызыл линия буенча урнашуы | <br>Шартлы билгеләр:<br>- мәдәни мирас объекты<br>1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Бина планында турыпочмаклы бер катлы кирпеч турыпочмаклы бинаның күләм-планлаштыру структурасы | <br>2 нче рәсем. Гомуми күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Конструктив схемасы: чын кирпеч диварлар; уемнарның чын кирпеч тоташтырмалары | <br>3 нче рәсем. Конструктив схемасы |
| 4. | Тарихи конфигурациясе, биеклек билгеләре һәм иңкү түбәсенең конструктив чишелеше, түбә материалы – ике фальцлы табаклы түбә тимере | <br><br>4-5 нче рәсемнәр. Түбә конфигурациясе |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Бина фасадларының архитектур бизәлеше:<br>1) төп фасад: төп фасадның үзәк уемы җәя формасында, калаклар белән кысаланган һәм ике ягында да җәя формасындагы тәрәзә уемнары белән симметрияле композиция, чыгып торган цоколь, йозак ташы һәм иңбашлары булган өчпочмаклы сандриклы катлаулы булмаган йөзлекләр белән кысаланган җәя формасындагы тәрәзә уемнары, тәрәзә төбендәге филенкалы турыпочмаклы куышлар, почмаклы рустован калаклар, бизәкләр тасмасы булган баскычлы кәрниз, иңбашлары һәм аркалы үзәк куышы булган кәкре сызыклы аттик һәм сохари белән тәмамланучы кәрниз, почмак баганалары булган парапет койма;<br><br>1) ян фасад: баскычлы кәрниз, бизәкләнеш (кирпеч буенча буяу) | <br><br>6 нчы рәсем. Төп фасад<br><br><br>7 нче рәсем. Аттик, кәрниз<br><br>8 нче рәсем. Фасадның сул өлеше (пилястра, тәрәзә уемнары, кәрниз) |

| | | |
|---|---|---|
| | |  9 нчы рәсем. Фасадның уң өлеше (пилястра, тәрәзә уемнары, кәрниз)   10 нчы рәсем. Фасадның үзәк өлеше (ишек, ишек уемы, кәрниз) |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Металл тәрәзә капкачлары һәм фурнитура һәм кыстыргыч элементлары белән капкалар | <br><br>11-12 нче рәсемнәр. Япкычлар һәм капкалар |